Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

23.01.2020 Менделеевск ш. № 40

Менделеевск муниципаль районының
алкоголь базары торышын җайга салу буенча
координация советының эш планын
һәм составын раслау турында

Менделеевск муниципаль районында лицензияле алкоголь продукциясен, шул исәптән Татарстан Республикасы алкоголь продукциясен реализацияләүне арттыру максатларында Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Менделеевск муниципаль районының алкоголь базары торышын җайга салу буенча координация советы составын расларга (1 нче кушымта).
2. Менделеевск муниципаль районының алкоголь базары торышын җайга салу буенча координация советы турындагы Нигезләмәне расларга (2 нче кушымта).
3. Менделеевск муниципаль районының алкоголь базары торышын җайга салу буенча координация Советының эш планын расларга (3 нче кушымта).
4. Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 24 июлендәге 461 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendelevsk.tatarstan.ru «Документлар» бүлегендә бастырып чыгарырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.А.Абдуллин

Кушымта
Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 23 гыйнварындагы
40 номерлы карарына

Менделеевск муниципаль районының
алкоголь базары ситуациясен җайга салу буенча
координация Советы составы

| | |
|---|---|
| Рәис | - Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең стратегик үсеш буенча урынбасары О.Е.Колпаков; |
| Урынбасар | - Икътисад, Сәнәгать һәм эшмәкәрлеккә ярдәм итү бүлеге башлыгы Л. А. Гәрәева; |
| Секретарь | - Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты торак сәясәте бүлеге, шәһәр хуҗалыгы һәм сәүдәсе баш белгече Р.Р. Гусейнов; |

Координацион совет әгъзалары:

ГАУЗ «Менделеевск үзәк район хастаханәсе» баш табибы (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе Чаллы территориаль органының контроль-инспекция бүлеге консультанты (килешү буенча);

Менделеевск муниципаль районы башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе (килешү буенча);

Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары;

Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсенең Менделеевск районара тикшерү бүлеге җитәкчесе (килешү буенча);

Россия Эчке эшләр министрлыгының Менделеевск районы буенча бүлеге башлыгы (килешү буенча).